**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 296 от 18.12.2024

**«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты **карар итә :**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2024елның 11 декабрендәге 293 номерлы карарына “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында”гы карарына, 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына

-составы учреждение директоры тарафыннан раслана торган өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ укучыларның кайнар туклануын оештыру буенча комиссия төзергә;

-"Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр" 2.4.3648-20 номерлы Санитар кагыйдәләр нигезендә һәм "Халыкны җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" СанПиН 2.3/2.4.3590-20 номерлы Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә туклануны оештыруны контрольдә тотарга.”.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында (https://apastovo.tatarstan.ru/) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

**Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.З. Зәмдиханов**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты Исполнительный комитет Апастовского муниципального района Республики Татарстан
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ ОТДЕЛ